ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 1, с.Р.Азелеево,
Зеленодольский район, 422512

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 1, Р. Әҗиле авылы,
Зеленодольск р., 422512

Тел.факс: (84371) 2-68-25. E-mail: Razl.Zel@tatar.ru, www.zelenodolsk.tatarstan

# КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары №1

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җеназа эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җеназа эшләре турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 119 номерлы карары белән, Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. 1 нче кушымтага һәм 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7 793,48 суммасында билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 нче номерлы карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск

муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Рус Әҗәле авыл жирлеге башлыгы Г.Ф.Семахина

Зеленодольск муниципаль районы
Рус Әҗиле авыл жирлеге башкарма
комитетының 2023 елның
31 гыйнварындагы 1 нче номерлы
карарына1 нче кушымта

**2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл жирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 247,07 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 1 209,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |

Зеленодольск муниципаль районы
Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма
комитетының 2023 елның
31 гыйнварындагы 1 нче номерлы
карарына1 нче кушымта

**2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне гыйбадәтләү | 750,35 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3 496,72 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 1 209,84 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |